ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

41-19; e-mail: Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

11 ноябрь 2022 ел № 17

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге гражданнарының карарларын тормышка ашыру максатыннан

2022нчы елның 17 октябрендә кабул ителгән 1 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге составына керүче Васильево торак пунктында 2023елга үзарасалым кертү турында”;

2022 нчы елның 17 октябрендә кабул ителгән 2 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге составына керүче Васильево торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башкарма комитеты;

2022 нчы елның 17 октябрендә кабул ителгән 3 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге составына керүче Ишки торак пунктында 2023 елга үзарасалым кертү турында”;

2022 нчы елның 17 октябрендә кабул ителгән 4 нче номерлы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге составына керүче Ишки торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башкарма комитеты;

К а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес

буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге
Советы рәисе Р.К.Хафизов

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге Башкарма комитетының
11.11. 2020 ел, 17 санлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2023 елның 28 мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1һәм 2 группа инвалидлар,күп балалы гаиләләр, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге Башкарма комитетының
11.11. 2020 ел, 17 санлы карарына
2 нче кушымта

_______________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и. ________________________________________________________________________________
___________________________________________________________________

Адрес: ________________________________________________________________

Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегенең ___________ авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2021 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 26.03.2021елга кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ______ сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:

Кабул итүче як банкы БИК ________________________________________
Сч. № ____________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ____________________________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК _______________ ОКАТО ___________________
Түләүнең билгеләнеше: гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче __________________ __________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - -**

_________________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*

_________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № __________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и. ___________________________________________________________
Адрес:______________________________________________________________
«__» ________________ 20__ г. ________________________________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегү шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)____________________
авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.